Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының
Татар Талкышы авыл җирлеге башлыгы
Карары

2020 елның 30 октябре                                                                                 № 7

«Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Татар Талкышы авылында гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Чистай муниципаль районының «Татар Талкышы авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең 22 статьясы нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. 2020 елның 18 ноябрендә 13.00 сәгатькә мәдәният йорты бинасында Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Татар Талкышы авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын түбәндәге адрес буенча билгеләргә: Татарстан Республикасы, Чистай районы, Татар Талкышы авылы, Совет ур., 4 нче йорт.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«2021 елда Чистай муниципаль районы Татар Талкышы авыл җирлегенең Татар Талкышы авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән үзара салым кертүгә, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарыннан, сугыш хәрәкәтләрендә катнашучыларның тол хатыннарыннан, күпбалалы гаиләләрдән, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 700 сум күләмендә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән ризалашасызмы:

- Комсомол (бер коены урнаштырып 63 мм торба диаметры), Совет (бер коены урнаштырып 110 мм торба диаметры) урамнары буйлап су белән тәэмин итүнең тышкы челтәрләрен төзү һәм ремонтлау, килешүләр буенча эшләр өчен түләү

«ЯКЛЫ»                                                  «КАРШЫ».

3. Җыенны оештыручы итеп Чистай муниципаль районының Татар Талкышы авыл җирлеге Башкарма комитетын билгеләргә.
4. Әлеге карарны авыл җирлегендә яшәүчеләрне күпләп җыелган урыннарда, игълан итү стендларында һәм такталарында элү юлы белән игълан итәргә, шулай ук Чистай муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Чистай муниципаль районының
Татар Талкышы
авыл җирлеге башлыгы                                                                 М.М. Вәлиев